СОВЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 2 июле** Болгар ш. **№ 11-4**

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 15 статьясындагы 4 өлеше, «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Спас муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2019 елның 29 июлендәге 40-9 номерлы карары нигезендә Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен үтәүне тәкъдим итәргә:

- социаль наем шартнамәсе төзү;
- муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшыру.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары белән тапшыру турында килешүләр төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны закон белән билгеләнгән вакытта Спас муни-ципаль районының рәсми сайтында (http://spasskiy.tatarstan.ru/) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Спас муниципаль районы башлыгы урынбасары С.И.Тюнев